**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1029

г. Казань

2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1029.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1029 нчы карары белән расланды

**2016 елга Татарстан Республикасы**
**дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның**
**фаразланган планы (программасы)**

I бүлек.
2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру тармагында дәүләт сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре

2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планы (программасы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып эшләнде.

2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) тормышка ашыруның төп максаты булып Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең максималь нәтиҗәле һәм керемле булуын тәэмин итү тора.

Татарстан Республикасын икътисадый үстерүнең өстенлекләрен исәпкә алып, 2016 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру тармагында дәүләт сәясәтенең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

житештерү-инновация структураларына инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итү кысаларында 2016 елда Татарстан Республикасы милкендәге акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен, аларны ачык аукцион сатуларында сату юлы белән яки акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына кертү юлы белән хосусыйлаштыру планлаштырыла.

2016 елда хосусыйлаштырудан Татарстан Республикасы бюджетына кергән керемнәр күләме 3 млн. сум дип көтелә.

Әлеге Фаразланган планга кертелгән һәм финанс елы тәмамланганда хосусыйлаштырылмаган дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

## II бүлек.
## 2016 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте

### 2016 елда акцияләрен хосусыйлаштыру планлаштырылган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

| Акционерлык җәмгыяте исеме | «Алтын акция» булу | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, % | Хосусыйлаштырылучы акцияләр пакеты (өлеше), % |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | | | |
| «Түбән Кама ресурлар» АҖ | юк | 11,99 | 11,99 |
| «Түбән Кама шин» ГАҖ | әйе | 0,196 (гади акцияләр) | 0,196 |
| | | 0,00017 (өстенлекле акцияләр) | 0,00017 |
| «Казан оптика-механика заводы» АҖ | әйе | 0,277 (өстенлекле акцияләр) | 0,277 |
| «КНИАТ» инновацион-технологик үзәге» сәнәгать технологияләре технопаркы» АҖ | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| «ОБОРОНПРОМ» берләшкән сәнәгать корпорациясе» АҖ | юк | 4,67 (1 454 965 данә) | 4,67 (1 454 965 данә) |
| Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | | | |
| «Крутушка» шифаханәсе» АҖ | юк | 19,27 | 19,27 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | | | |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ААҖ | әйе | 7,69 | 7,69 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| «2 нче Бөгелмә икмәк продуктлары комбинаты» ЯАҖ | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| «Бөгелмә элеваторы» ЯАҖ | юк | 25% + 1 акция | 25% + 1 акция |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | | | |
| «Химия технологияләре тармагында төбәк инжиниринг үзәге» АҖ | юк | 99,45 | 49,44 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | | | |
| «Дәрвишләр бистәсе» 9 нчы стоматология поликлиникасы» ААҖ | юк | 48,41 | 48,41 |
| Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | | | |
| «АК БАРС» БАНК» ГАҖ | юк | 14,57 | 6,3051 |